ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Татарстан Республикасының» сүзләрен «1. Татарстан Республикасының» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү очраклары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү;

һава юлы суднолары белән гамәлгә ашырыла торган санитария-авиация эвакуациясе хезмәтләре күрсәтү;

агымдагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнаша торган һәм мәҗбүри

медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек башкармый торган медицина оешмалары тарафыннан җенси юл белән тапшырыла торган, кеше иммунодефициты вирусы китереп чыгарган авыруларда, барлыкка килгән иммунодефицит синдромында, туберкулезда, психик тайпылышларда һәм тәртибендә тайпылышларда күрсәтелә торган беренчел медицина-санитария һәм махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү;

халыкка туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә турыдан-туры катнаша торган Татарстан Республикасы медицина оешмаларының медицина, фармацевтика хезмәткәрләренә һәм педагогик хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә кызыксындыру характерындагы ай саен акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекчәләре күчмә бригадалары машина йөртүчеләренә, шулай ук Татарстан Республикасы медицина оешмаларының паллиатив медицина ярдәме бүлекчәләре машина йөртүчеләренә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә интенсив хезмәт өчен өстәмә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру;

паллиатив медицина ярдәме күрсәтү;

балалар шифаханәләре шартларында балаларны сәламәтләндерү буенча чараларны тормышка ашыру;

идентификацияләү мөмкин булмаган һәм мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелмәгән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелгән авырулар һәм хәлләр вакытында ашыгыч һәм кичектергесез рәвештә медицина ярдәме күрсәтү;

Татарстан Республикасы законнары нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлау һәм ишетү органнарын протезлау буенча хезмәтләр күрсәтү;

«Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе тарафыннан медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша өстенлекле бер канал аша финанслауны башкару чараларын гамәлгә ашыру кысаларында идарә итү функцияләрен үтәү.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 13 ноябрь
№ 67-ТРЗ